وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا


Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№12 (155). 21 сентябрь 2012 / 5-зөлкагдә-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Коръәндәге риторик дәлилләр ▷2◁



Камаллылар Туфан Миңнуллинның "мулла"сын көрәшче итеп күрә ▷3◁



"Сабыйга" акциясе башлана! ▷4◁

## Бәхәсле фильм коткысына бирешмик!

**Һичшиксез, Рәсүлебез Мөхәммәд (сгв) шәхесе һәр мөселман өчен дә беренче урында тора. Һәм беребез дә аңа карата әйтелгән начар фикерләрне тыныч кабул итә алмый. Ләкин, Пәйгамбәребез (сгв) мөселманнарда мондый ярсуны хуплар иде микән?! Ул үзе бик тыйнак кеше булган, аның яһүд күршесенә карата мөнәсәбәтен искә төшерү дә җитә.**

Икенче мисал - хатынын зина кылуда гаепләгәндә дә үзен бик тыныч тота. Хәтта ызгыш китереп чыгарган, Мәккәдә монафикъ буларак танылган Габдулла ибн Убаяга бернинди җәза да бирми.

Бүген исә без, мөселманнар, кызу канлыга әйләндек, теләсә кайсы очракны сәбәп итеп кызып китәргә әзербез. Нәтиҗәдә, безнең кызулыкны безгә каршы кулланалар да. Америкада Мөхәммәд пәйгамбәргә (сгв) кагылышлы бәхәсле фильмның чыгуы - финанс-сәяси даирәдәге билгеле берәүләрнең үз мәнфәгатьләренә ирешер өчен алдан уйланылган коткысы, мөгаен. Бәлки Президент Обаманы башкага алыштыру вакыты җиткәндер, ә бәлки бүтән сәбәпләр шундый фильм әзерләүгә этәргәндер?! Әйтик, ни өчен бу фильм ике ай дәвамында (интернетта киң таралган "Ютуб" чыганагында) беркемнең дә игътибарын җәлеп итмәгән соң? Ни сәбәпле анда тавыш өстенә тавыш яздырылган?

Фильм төшерүчеләрнең төп максаты мөселманнар хәтерен калдыру булса да, нигә алар белән заманча, судка биреп эш итмәскә, гафу үтенүләрен сорап, рухи зыян өчен компенсация сорамаска? Әгәр дә алар бер тапкыр булса да үз гамәлләре өчен акча түләсәләр, башка вакытта бүтәннәр өчен бу сабак булыр иде.

***Габдулла хәзрәт ӘДҺӘМОВ, Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары***



## Аксубай һәм Баулы имамнарына шәһадәтнамәләр тапшырылды

**20 сентябрь көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә Аксубай һәм Баулы районнары дин әһелләренә имам-хатыйблык вазифасын раслаучы шәһадәтнамәләр бирелде. Шәһадәтнамәләрне мөфти вазифаларын башкаручы Габдулла хәзрәт Әдһәмов тапшырды. Шәһадәтнамәләр тапшыру тантанасында әлеге районнарның мөхтәсибләре һәм авыллардан килгән утыздан артык имам катнашты.**

Габдулла хәзрәт имам-хатыйблык вазифасын аңлатып болай диде: "Җәмгыятебезне төрле чирләрдән кем дәвалый ала? Фәкать динебез генә. Матди чирләр урынына дин рухи азык тәкъдим итә. Әгәр дә кеше күңелендә Аллаһы Тәгаләгә карата хакыйкый дөрес мәхәббәт булса, ул пычрак гамәлләрдән тыела. Ә рухи азыкны халык каян ала соң? Имамнардан. Безнең дәрәҗәбез югары һәм шул ук вакытта бик җаваплы, авыр. Хәдистә хәерле бәндә дип, Коръәнне өйрәнеп, башкаларга өйрәтүче атала. Динебезне өйрәнеп, башкаларга өйрәтү - безнең турыдан-туры вазифабыз. Пәйгамбәребез (сгв) бер киңәш бирә: "Аллаһы Тәгаләнең юлына хикмәт һәм матур вәгазь белән күндер". Һәркайсыбыз, авылларда Диния нәзарәтенең бер вәкиле. Үзара бердәм булып, динебез кыйммәтләрен халыкка җиткереп эшлик".

Белгәнебезчә, Коръән басылуга 225 ел тулу уңаеннан, агымдагы ел ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан Коръән елы дип игълан ителде. Нәзарәт көче белән Изге Китапның Казан басмасы 10 мең тираж белән нәшер ителде. Ул халкыбызның могтәбәр шәхесләренә бүләк ителде, шулай ук аны республикабызның һәр имамына җиткерү бурычы куелды. Шул ниятне тормышка ашыру максатыннан шәһадәтнамәләр тапшыру тантанасында Казан басмасы Аксубай һәм Баулы районы муллаларына да бүләк итеп бирелде.

# ФЕТНӘ

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллә-ллаһу галәйһи үә сәләм (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) өч тапкыр:**

***"Валлаһи, фетнәләрдән ерак торганнар бәхетледер"***, - дигән. (Әбу Давыд)

"Фетнә" сүзе гарәпчәдән "гауга", "фикерләр каршылыгы", "таркалу" дип тәрҗемә ителә. Шундый юньсез күренешнең мөэминнәр арасында да булып торуын күрү - гадәттән тыш аяныч. Гәрчә безнең фетнәдән котыла алмавыбыз турында Ислам барлыкка килү вакытында ук әйтелгән булса да, барыбер, мөэмин-мөселман апа-сеңелләрнең, башка туганнарның, үзара аңлашуларын югалтып, конфликтларга (һәм еш кына хәрби конфликларга да) кереп батуларын күрү - түзеп торгысыз авыр. Ислам - тынычлык, якыныңны ярату дине бит. Безнең арада булып торган мондый хәлләр - һич тә Аллаһы Тәгаләбезнең дине андый булу аркасында түгел, ә безнең җаһил, зәгыйфь, Аллаһтан курку тойгысын югалткан коллары булуыбыздан. Әгәр дә без үзебез башкачарак булсак, без Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!): ***"Бер-берегез белән араларны өзмәгез, бер-берегезне кире какмагыз, бер-берегез белән ызгышмагыз, бер-берегезгә хөсетлек һәм көнчелек кылмагыз, Аллаһның коллары - туганнар булыгыз! Бер мөэмингә икенче бер мөэмин белән өч көннән артык сөйләшмичә, үпкәләп тору килешми"*** *(Бохари, Мөслим)*, - дигән сүзләрен искә төшергән булыр идек. Һәм дә без, фетнә алдында безнең сакланусыз калуыбыз турында сөйләп, фетнә - имансызларга гына түгел, ә ... бүтәннәргә дә яный дип әйткән Раббыбызны ачуландырудан куркыр идек... Мөселманнар арасындагы беренче сугыш Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сәхабәләре яшәгән вакытта ук булган һәм бик авыр эз калдырган.

Хөзәйфә болай дип сөйләгән: "Инсаннар гадәттә Аллаһның Рәсүленнән (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) яхшылык турында сорадылар, ә мин, миңа очрар дип шикләнеп, яманлык турында сорадым. Мин: "Аллаһның Илчесе, без чынлап та җаһиллектә һәм яманлыкта булганбыз, ә аннан соң Аллаһы Тәгалә безгә яхшылык бүләк иткән, ләкин моннан соң да яманлык киләчәкме?" - дидем. Ул: "Әйе", - диде. Шунда мин: "Ә бу яманлыктан соң яхшылык килерме соң?" - дип сорадым. Ул: "Әйе, ләкин бу яхшылыкка яманлык катнашкан булыр", - диде". (Бохари, Мөслим)

Бары тик Кыямәт көнендә генә мөэминнәр арасындагы таркалышка кемнең гаепле икәне ачыкланыр; читтән карап кына, кешеләрнең күңеленә үтеп керми торып, хөкем йөртүе кыен; ләкин, кем мөэминмөселман туганына кылыч күтәргән, барысына да җавап бирергә туры киләчәк, чөнки, һәрвакытта да, тукталырга мөмкинлек бар.

Ә җаваплылык дәрәҗәсе бик зур (мәгънәсе): "Кем дә кем мәкер белән мөселманны үтерсә, эчләрендә дөрләп ут янган җәһәннәм аның җәзасыдыр. Ул анда дәвамлы калачак. Аллаһ аңа газап бирер, ләгънәт орыр вә аның өчен авыр җәза әзерләр" ("Ән-ниса (Хатыннар)" сүрәсенең 93 нче аяте).

Әгәр ике мөэмин очрашып,

*(Ахыры 3 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### АПАНАЙ МӘДРӘСӘСЕ СҮТЕЛМӘЯЧӘК

**Татарстан буенча дәүләт милке белән идарә итүче Федераль агентлыкның җирле хакимияте Апанай мәчетенең "Касыймия" мәдрәсәсе бинасын җимерү турындагы мәгълүматны кире какты.** Бу хакта "Ислам.-ру" мәгълүмати каналы хәбәр итә. Исегезгә төшерәбез: мәдрәсә җитәкчелеге, бина янында бульдозерлар күргәч, куркуга калган иде. Моны мәдрәсә янында ачылырга тиешле, күптән түгел генә төзекләндерелгән Дәүләт милке идарәсен ачу өчен барган әзерлек эшләре белән бәйләп аңлатканнар.

Татарстан буенча дәүләт милке белән идарә итүче Федераль агентлыкның җирле хакимияте хәбәр иткәнчә, мәдрәсә янындагы мәйданда тирә-якны төзекләндерү эшләре башкарылды. Бу эшләр барышында 1970 елларда рөхсәтсез төзелгән ярымҗимерек биналарны сүткәннәр. Бинаны җимерү вакытында мәдрәсә бинасына зыян килмәгән. Хәзер чистартылган урынны яшелләндерәләр.

### МИНИСТРЛЫК ТӘКЪДИМ БЕЛӘН ЧЫКТЫ

**Тәмәкене ваклап сату законсыз, чөнки сатып алучы үз ихтыяры белән түгел, ә бәлки, никотинга бәйлелек белән эш итә.** Бу турыда РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы "Халыкны тәмәке төтене зарарыннан саклау һәм тәмәке тартуның нәтиҗәсе" дип аталган закон проектына биргән аңлатмасында әйтелгән. Бу хакта "Lenta.ru" хәбәр итә.

Килешүгә үз ихтыярың белән килмәгән очракта Россия Федерациясенең Гражданнар кодексы нигезләмәсе бозыла. Моннан тыш, тәмәке сату сатып алучының "Сатып алучылар хокукын саклау" законында күрсәтелгән сәламәтлеккә һәм кеше тормышына зыян китермәүче продукция сатып алу хокукы бозыла.

"Халыкны тәмәке төтене зарарыннан саклау һәм тәмәке тартуның нәтиҗәсе" закон проекты 2012 ел башында эшләнелгән. Бу документ ябык бүлмәләрдә, поездда, эш урыннарында, вокзалларда тәмәке тартуны тулысынча тыя.

Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы тәмәке рекламасын тыярга, шулай ук тәмәке җитештерүче компанияләргә иганәче булырга, тәмәкене бушлай таратырга яки ташламалар белән сатарга рөхсәт итмәскә тәкъдим итә.

### АЧЫК ДӘРЕС УЗДЫ

**Казанның Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә "Экстремизмга юл юк!" темасына багышланган ачык дәрес узды.**

Ачык дәресне мәдрәсә укытучысы Рамил хәзрәт Бикбаев үткәрде. Ул шәкертләргә экстремизм турында, аңа ни рәвешле каршы тору кирәклеге хакында сөйләде.

Уку йортында белдерүләренчә, мәдрәсәдә мондый ачык дәресләр беренче генә ел үткәрелми. Анда экстремизмга каршы көрәш мәсьәләләренә зур игътибар бирелә: төрле чаралар уздырыла, брошюралар басыла.

### ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!

**1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# МУЛЛА ШАГЫЙРЬ

**Мөхәммәдсадыйк Шаһиәхмәт улы Иманколый 1870 елда Казанда мулла гаиләсендә дөньяга килә. Аның әтисе Казанның сигезенче мәчете (Яңа бистәдәге Кечкенә мәчетнең) имамы, китапка гашыйк кеше була. Ш.Мәрҗани аның хаҗ сәфәреннән бик күп китаплар алып кайтуына махсус тукталып үтә. Шаһиәхмәт үзе дә каләм иясе булган. Ул - Ш.Мәрҗанинең "Нәзурәтел хак" исемле китабына каршы зур тавыш тудырган "Җәрүдә" китабын бастырган кеше.**

Мөхәммәдсадыйк хәзрәт аның яшь хатыныннан туган, күрәсең - малае туганда аңа 67 яшь була. Улына сигез яшь тулганда, ягъни 1878 елда мулла дөнья куя. Вафатыннан соң, әҗәт-бурычларын түләү өчен, җыйган акчалары гына җитми, гаилә әгъзалары мулланың бөртекләп җыелган өй җиһазларын, хәтта китапханәсен дә сатарга мәҗбүр булалар. Атасыз һәм милексез калган малай матди яктан авыр тормышта үскән булырга тиеш. Шуңа күрә, бар ышаныч - уку, белем алуда. Ул үсмер чагында ук башка сыймаслык мөстәкыйль карарга килә - кесәсендә бер тиен булмаган хәлендә Бохарага белем эстәргә юл тота. "Үз әхвалем" дигән шигырендә язуына караганда, бу вакытта аңа 14 яшь тула. (Ләкин хакыйкать өчен искәртик, бу хәл һиҗри белән 1303 елда, 1886 елның җәендә, Мөхәммәдсадыйкка 16 яшь тулган көннәрдә була.)

Казаннан кузгалып, ул ике көндә пароход белән Самарага, аннан поезд белән Ырынбурга килеп җитә. Анда ике атналап мәдрәсәдә яшәп, байлар иганәсе ярдәмендә дөя кәрванында Казалы шәһәренә юнәләләр. Утыз өч көн дигәндә анда да барып җитәләр, тагын егерме ике көннән Бохарага да барып ирешәләр. Шулай итеп, мәдрәсәгә урнашып, гаять авыр шартларда укый башлый.

Шул шартларда ул Бохарада сигез ел белем ала. 1894 елда Бохарадан хәзерге Красноводский шәһәренә поездда килеп, аннары Каспий һәм Идел буйлап пароходта Казанга кайтып төшә һәм Яңа бистәнең алтынчы мәчетенә, Зариф Әмирхан белән берлектә, шәрик мулла булып урнаша. Соңрак ул гади мулла гына булмыйча, каләм иясе һәм галим буларак та таныла. Ул "Тәрҗемәи руси, фарси вә төрки" дигән сүзлек төзеп, аны 1909, 1913, 1917 елларда кат-кат бастыра. 1910 елда 744 битле "Коръән тәфсире"н әзерләп бастырып чыгара. Башка хезмәтләре дә билгеле. Әмма, башка муллалардан аермалы буларак, Мөхәммәдсадыйк хәзрәт байлык та, зур шөһрәт тә казана алмаган.

Әйтергә кирәк, татар руханилары көнкүрештә киң катлау крестьяннардан әллә ни аерылмаганнар - алар да иген иккәннәр, мал асраганнар. Әмма рухани катламыннан булган әһли голамә, тулаем алганда, тормыш турында тирәнрәк уй-фикер йөртергә сәләтле булулары белән башкалардан аерылып та торганнар. Шул яктан алар крестьяннарның аңфикер үсешенә сизелерлек йогынты ясаганнар. Мөхәммәдсадыйк Иманколыйның иҗаты исә шул тормышны күзәтү, шул хакта уйлану үрнәге ул. Шагыйрь илдә барган хәлләр хакында милләт, халык язмышы югарылыгына күтәреп уйлана. Аның иҗатына конкрет бер чорның, нәкъ менә XX йөзнең 20 нче еллары моң-зарын чагылдыру хас.

Мөхәммәдсадыйк Иманколый шигъри мирасының яртысын диярлек дини эчтәлектәге шигырьләр тәшкил итә. Ә менә дөньяви темаларга язылган кайбер әсәрләрендә ул, безнеңчә, шул чор татар милли аңы үсешендә яңа бер сәхифә ача. Аның бу казанышының мәгънәсен дөнья мәдәни хәрәкәтенең шул юнәлештәге казаныш-табышларына бәйләп, шуңа нисбәтән рәвештә аңлап һәм аңлатып булыр иде.

***Мәсгуд ГАЙНЕТДИН,***
***филология фәннәре докторы***

2012 ЕЛ - ТАТАРСТАНДА КОРЪӘН ЕЛЫ

# Коръәндәге риторик дәлилләр

**Мәгълүм булганча, Коръән теленең стиле илаһи сүзнең тулаем максатыннан - иманның хаклыгына инандыру һәм аның таләпләренә күндерүдән чыгып билгеләнә. Коръән, милләтенә, тән төсенә, тумышына, белем дәрәҗәсенә карамастан, һәммә инсанга өндәмә рәвешендә яңгырый. Кешеләрнең мәгълүматны төрлечә кабул итүләренә дә карамастан, әлеге мәгълүмат аларның үз тәҗрибәләренә таянып үзләштерелмәгән очракта да, изге текстның хаклыгына ышандыра торган дәлилләре бик күп. Белгәнебезчә, тезисның дөреслеген чагылдырган сөйләм кисәген (фрагментын) без риторик дәлил дибез.**

**КОРЪӘН** текстында риторик дәлилләрнең электән үк билгеле булган төрләре (архетиплары) очрый дигән мәгълүмат бар. Әлеге карашны куәтләп, галим әз-Зәркани Коръәндәге дәлилләрнең катлаулы фәлсәфи раслауларга, калыплашкан һәм мантыйк кагыйдәләренә генә нигезләнмәвен дә искәртә. Галим бу фикерен ике сәбәп белән аңлата. Беренчедән, Коръән иңдерелгән заманда гарәпләр үзара аралашуда бу төр дәлилләрне кулланмаганнар, чынлыкта, Коръән аларның сөйләм үзенчәлекләренә нигезләнә: "*(Аллаһның әмерләрен)* Ана телендә яхшылап аңлатсыннар дип, *(үз араларыннан)* пәйгамбәрләр күндердек. Аллаһ *(мөселман булырга)* теләмәгәнне адаштырыр, теләгәнен тугры юлга чыгарыр. Аллаһ көч һәм хикмәт иясе" ("Ибраһим" сүрәсенең 4 нче аяте). Икенчедән, катлаулы фәлсәфи раслаулар күп кешегә тиз генә аңлашылмый, аларга нигезләнү үзеңнең хаклыгыңны башкача аңлата алмаганда гына максатчан була.

Коръән текстын өйрәнү барышында күпчелек дәлилләрнең максатлы, төпле раслауларга нигезләнгәнлеге күренә, без дә аларны мантыйкка ярашлы (логик) яки мәгънәви дәлилләр дип атарбыз. Алар, беренче чиратта, акыл көченә инанган фикерләрнең мәгънәсен ачык сиземли торган, аларның хаклыгы ышанырлык дәлил булуына төшенә алган аудиториягә юнәлтеләләр. Мәгънәви дәлил буларак, Аллаһның җиһанны яралтучы булуын раслаган мисалны күзәтеп үтик. "Әллә алар үзләреннән-үзләре барлыкка килдеме? Әллә алар үзләре юктан бар итә аламы? Әллә соң күкләр белән Җирне алар юктан бар иттеме? Хәер, алар *(Аллаһның кодрәтенә)* ышанмый" ("Тур (Тау)" сүрәсенең 35-36 нчы аятьләре). Мәһабәт сарай, тирә-янындагы гүзәл бакча яныннан үткәндә, акылында булган кеше аларны үзләре барлыкка килгән дип әйтми. Сарай үзен-үзе төзегән, агачлар үзләрен-үзләре үстергән дип әйтү бигрәк тә ахмак фараз. Бу очракта, оста нәкышчылар, төзүчеләр, бакчачылар хезмәт куйганлыгы хакында һичнинди шик-шөбһә булуы мөмкин түгел. Әлеге мантыйкка ярашып, Коръән кешеләрне Аллаһның күк һәм җирне булдыручы икәнлегенә инандыра.



Аятьләрдә Аллаһның бердәнберлеген башка төр мәгънәви дәлилләр белән аңлатылуын да очратабыз: "Аллаһ бернинди дә баланың атасы булмады. Аңа тиң башка бер илаһ та юк. Әгәр булса, һәр илаһ үзе яралткан малны һәм идарәне үз кулына алырга тырышыр иде һәм, мотлак, алар бер-берсен җиңәргә тырышып, сугышырлар иде. Субханаллаһ! Аллаһ алар (мөшрикләр) табынганнардан өстен" ("Мөэминун (Мөэминнәр)" сүрәсенең 91 нче аяте). Бу аятьтә китерелгән тезис киресен әйтү алымы белән раслана. Әйтик, Җиһан берничә тиңдәшсез Аллаһ кодрәте белән оешкан һәм алар үзләренә генә буйсынуны таләп итәләр, ди. Бу очракта алар арасында кискен каршылык башланып, үзара көрәш яки берсенең генә тулаем җиңүе яки Җиһанның җимерелүе белән тәмамланыр иде. Башка сүзләр белән әйткәндә, Коръәндә язылганча, Җирдә һәм галәмдә искиткеч тәртип, ритм саклануы, Аллаһның бердәнберлегенә инандыра торган дәлил. Кабул ителгән карарларның, хәл ителгән мәсьәләләрнең кулайлыгына, файдасына кагылышлы логик дәлилләр дә бик кызыклы. Мәсәлән: "Аллаһка вә Ахирәт көненә иман китереп, үзләренә Аллаһ тарафыннан бирелгәнне (дин юлында) сарыф итсәләр, ни була иде инде? Аллаһ аларның хәлен бик яхшы белеп тора" ("ән-Ниса (Хатыннар)" сүрәсенең 39 нчы аяте).

Һәркем нindидер карарга үзбелдегенчә килә, нindидер мәсьәләне үзенчә хәл итәргә хокуклы. Кешеләр инанып, Аллаһның ихтыярына буйсына яки имансызлык чоңгылына тәгәри ала. Бары тик үзләренең язмышыннан ваз кичә яки нindидер тарафны сайламый кала алмыйлар. Җирдә, иман китереп, лаеклы яшәгән кешеләр, ахирәттәге тормышның юклыгын фаразлаганда, нәрсә югалталар соң? Намуссызлык юлында, гөнаһ кылып, әшәкелек таратып яшәүчеләр, Аллаһның вәгъдәсе дөрес булган очракта, нәрсәгә ирешәләр? Берәүләр һичнинди югалтуларга дучар ителмиләр, икенчеләре һәрнәрсәдән мәхрүм булачаклар. Аллаһка буйсынуның өстенлеген, Коръән, киресенә каткан имансызларга, шул рәвешчә аңлата.

Кешенең танып-белүен камилләштерүгә, аятьләрнең әһәмиятен аңлатуга юнәлдерелгән логик дәлилләр белән беррәттән, Коръәндә тыңлаучыларның рухи халәтенә, кичерешләренә йогынты ясарлык хисси дәлилләр дә очрый. Теге яки бу ышануларга һәм гамәлләргә хисси мөнәсәбәт оештырып, алар аудиториянең аңына сеңдерелергә тиешле фикергә җирлек әзерлиләр. Мәсәлән, Кыямәт көнендә имансызларның нинди очракта котылу мөмкинлекләрен аңлатканда: "Аятьләребезне ялганга чыгарып, үзләрен бөек күрсәтергә теләгәннәр бар, менә шуларга инде Күк капусы ачылмаячак һәм алар, дөя энә күзе аша узганга чаклы, җәннәткә кермәячәк. Гөнаһлыларны менә шулай җәзалаячакбыз", - диелә "Әгъраф (Пәрдә, калкулык)" сүрәсенең 40 нчы аятендә. "Кяферләрнең кулында Җир йөзендәге байлыкларның бөтенесе булса, хәтта икеләтә артык булса да, Кыямәт көнендә җәзадан котылу өчен шул байлыкны бирсәләр дә, кабул ителмәс. Алар өчен әче газап бар" ("Маидә (Табын)" сүрәсенең 36 нчы аяте).

Нигездә, хисси дәлилләр чит абруйга яки күпчелек фикеренә таянудан оеша. Мәккә мәҗүсиләре өчен язу таныган кешеләрнең - яһүдләр һәм христианнарның сүзе абруйлы саналган. Алдан күрүчәнлек турындагы кайбер фикерләрнең дөреслеген раслау максатыннан Коръәндә дә аларга сылтама китерелгән: "(Ий, Мөхәммәд) сиңа чаклы да Без вәхий тапшырылган кешеләрне генә пәйгамбәр итеп җибәрдек. Әгәр (бу турыда) белмисез икән, белгәннәрдән (китаплы халыктан) сорагыз ("Аятьтәге "әһлүз-зикр", ягъни "белгәннәр" сүзен, Тәүрат белән Инҗилне яхшы белгән кешеләр, китаплы халык, дип аңларга кирәк. Мостафа Чагрыҗы тәфсиреннән") ("Әнбия (Пәйгамбәрләр)" сүрәсенең 7 нче аяте). Чит абруйларга мөрәҗәгать итү очраклары аз, чөнки бу дәрәҗәдә хәлителә торган сораулар да бик чикле. Алай гына да түгел, кайбер очракларда, ялган шаһитлек мөмкинчелеген күзаллап, Коръән читтән булган дәлилләрне гаепләп чыга: "Үзләренә Китап иңдерелгәннәрне күрдеңме? Потларга (таш сыннарга, агач сыннарга), шайтанга ышаналар, соңыннан кяферләр өчен:

- Болар Аллаһка иман китерүгә караганда турырак юл, - дип сөйлиләр". ("ән-Ниса (Хатыннар)" сүрәсенең 51 нче аяте).

Аудиториягә дәлилләр, күпчелек фикеренә сылтама ясау Коръәндә, еш кына, пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) замандашлары күзаллауларына һәм ышануларына юнәлдерелгән. Мәҗүсиләр, Җиһанны бар иткән Аллаһның бердәнберлегенә ышанган хәлдә дә, гозерләрен уйлап чыгарылган аллаларга юнәлткәннәр. Коръәндә Аллаһның бердәнберлеген дәлилләүдә мәҗүсилектәге әлеге каршылыкларга мөрәҗәгать ителә: "Хактыр ки, алардан:

- Күкләрне вә Җирне кем юктан бар итте? - дип сорасаң, әлбәттә:

- Аллаһ бар итте, - дип әйтерләр. Әйт син аларга:

- Шулай булгач, әйтегез әле: Аллаһ миңа берәр төрле зарар кылырга теләсә, Аллаһны инкяр итеп, табынганнарыгыз Ул биргән зарарны китерә алачакмы? Яки Аллаһ миңа рәхмәт әйләсә, алар Аның рәхмәтен юкка чыгара аламы? - дип сора. Әйт син аларга:

- Миңа (ярдәм итәргә, мине сакларга) Аллаһ җитәр, - диген. Тәвәккәл итүчеләр бары тик Аңа инанып, аркаланалар" ("Зүмәра (Халык өере)" сүрәсенең 38 нче аяте).

Бу - мәҗүсиләр Җирдә һәм күкләрдә Аллаһның чикләнмәгән хакимлеген таныган очракта, таш сыннар да ярдәмгә килмәячәген, ялваруларына җавап кайтармаячагын белдерү өчен китерелгәнгә дәлил. Алдагы мисал риторикада шәхескә юнәлтелгән дәлил дип атала.

**(Ахыры киләсе санда.)**

***Гаптрәүф НУРИЕВ,***
***филология фәннәре докторы***

# МӘДРӘСӘЛӘРНЕҢ ТАТАР МӘГЪРИФӘТЕНӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ

## (XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы)

**(Ахыры. Башы газетабызның 14 сентябрь (№ 11) санында.)**

Мәдрәсәнең һәр каты билгеле бер вазифа үтәгән. Мәсәлән, беренче катта башлангыч сыйныфлар, ашханә, хезмәт күрсәтүче персонал өчен махсус бүлмәләр урнашкан булган. Икенче катта урта, югары (игдадия), әзерлек сыйныфлары, өченче катта йокы бүлмәләре һәм мәдрәсәгә махсус кушып төзелгән мәчет урнашкан булган.

Уфаның җәдиди "Галия" мәдрәсәсе дә югары абруй белән файдаланган. Аның диварларыннан татар, башкорт һ. б. төрки халыкларның каләм әһелләре, мәгариф-мәдәният хезмәткәрләре һ. б. өлкәдә танылган милләтпәрвәрләрнең тулы бер буыны тәрбияләнгән. "Конфессиональные школы" отчётын төзегән Я.Д. Коблов: "Бу фәннәрне өйрәнү нәтиҗәсендә, анда укучыларның акыл үсеше бик югары биеклеккә кадәр күтәрелә", - дип юкка гына билгеләп үтмәгән инде.

1911 елгы санда инглиз журналы "The Muslim world (Мөселман дөньясы)" җәдиди мәдрәсәләрнең уку планнарын анализлап: "Алар классик гимназия планнары белән охшашлар, бары тик грек һәм латин теле урынына аларда гарәп һәм фарсы теле", - дип билгеләп үткән.

СССР Министрлар Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты 1948 елның 10 февраль карары белән Казандагы "Мөхәммәдия", "Касыймия", Уфадагы "Галия", "Госмания", Оренбургтагы "Хөсәения", Троицкидагы "Рәсүлия" һәм Иж-Бубый мәдрәсәләрен, бу мәгариф уку йортларының алардагы белем бирү дәрәҗәсен һәм инкыйлабка кадәрге бу уку йортларын бетереп чыгучыларның хокукларын рәсми тану буларак, педагогик көллиятләргә, ягъни, махсус урта уку йортларына тиңләнгәннәр. Бу карарның зур символик әһәмияте бар.

Борынгы вакытлардан алып Октябрь инкыйлабына кадәр кулланылган уку дәреслекләре исемлеге дә гаять зур. Мәсәлән, 1917 елда цензорлык комитеты татар мәктәп-мәдрәсәләрендә 1911-1913 елларда кулланылган дәреслекләр буенча "Дәреслекләргә күзәтү" басмасын нәшер иткән. Бу "Күзәтү" дә татар телендә чыккан, элек нәшер ителгән һәм берничә тапкыр бастырылган "гомум кабул ителгән" 394 дәреслеккә анализ бирелгән.

Бу дәреслекләрнең 70 проценты дөньяви фәннәр буенча булган. Методик ярдәмлекләр дә бастырылган. Мәсәлән, Г.Коләхмәтов "Математика укыту методикасы" хезмәте бастырып чыгарган. Октябрьгә кадәрге чорда күп кенә татар галимнәре: Х.Корбангалиев, Я.Айманов, И.Хәмиди - табигать белеме; Д.Абызгильдин, М.Бәхтияр, Р.Ибраһимов - астрономия; Г.Фәхретдинов, И.Хәмиди - ботаника; Г.Шонаси - химия; Г.Гыйсмәти, Х.Зәбири - физика; И.Хәмиди, Д.Габидуллин, Х.Гайнелгибад - анатомия һәм гигиена; Г.Мәхмүди - логика; К.Насыйри, Г.Салихов, И.Сөләймани этика буенча һ. б. хезмәтләр язган.

Халык мәгарифенең уңышлары күзгә ташланып тора. Дөньяви мәгарифкә таба юл тоту кире борылмаслык юнәлеш ала. Иске караш тарафдарларын бик каты каршылык күрсәтүләренә дә, патша администрациясенең көчле басымына да карамастан, яңалык үз дигәнен эшли. Уку процессының европалашуы барлык уку-укыту эшчәнлеген үзгәртеп коруга юнәлтелгән тулы бер хәрәкәткә әйләнә. 1910 елга Казан губернасындагы бар татар мәктәпләренең 90 процентының укуга өйрәтүдә аваз (җәдиди) ысулына күчеп бетүе дә мондый тәрәккыятьнең бер күрсәткече булып тора.

1905 елга бер Казан губернасында гына да мәктәп һәм мәдрәсәләр саны 845 була, аларда 54549 укучы белем ала, шул исәптән 34860 малай һәм 19599 кыз бала. Губернадагы милли уку йортларының саны бер тайпылусыз артуын дәвам итә: 1907 елга аларның саны 877 гә (66787 укучысы белән), 1913 елга 967 гә (79496 укучы) җитә.

Патша хөкүмәте "башка милләт" мәгарифенең, бу мәгариф системасының европалашуы, тәрәккыять, милли яңарыш өчен тырышкан татар зыялылары кулында булуына ирек куярга теләмәгән. XIX йөз һәм XX йөз башында хөкүмәт татар халкы арасында, мәдрәсәләрдә рус сыйныфлары, татар телле балалар өчен рус мәктәпләре, авылларда рус-татар мәктәпләрен көчләп ачтыра башлый. Бернинди шик тә юк, 1914 елның августында I Бөтендөнья сугышы башланмаса, патша системасы, бик озак икеләнмичә, бар татар мәгарифенә үлем карары чыгарган булыр иде, татар мәктәп системасын теге яки бу дәрәҗәдә тәэмин итеп, милләтнең рухи яңарышына һәм күтәрелешенә ярдәм итеп торган бар чыганакларны да ябар иде. Халыкара кан коешка күчү шартлары гына патшаның чикләнмәгән хакимиятен армияне "туп азыгы" белән тәэмин итеп торган татар халкы муенындагы элмәкне бераз бушатырга мәҗбүр итә.

*Марат хәзрәт*
***МӘРДАНШИН,***
***тарих фәннәре кандидаты,***
***Ютазы районы имам-мөхтәсибе***

# ФЕТНӘ

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

дошман булып аерылалар икән, алар фетнә оештыралар дигән сүз. Чөнки аларның һәрберсе үз якыннарына килә дә, үзе килешә алмаган кешегә юнәлтелгән тискәре фикерләре, мөнәсәбәте белән бүлешә башлый. Шулай итеп фетнәдә уннарча кеше катнашып китә ... аннан соң да шулай дәвам ителә.

Аллаһы Тәгалә (мәгънәсе): "Сез шундый фетнәләрдән куркыгыз, ул фетнәләр бары тик залимнәргә генә кагылмас (барыгызны да тар-мар итәр), белегез ки, Аллаһның газабы дәһшәтледер" ("Әнфал (Табыш малы)" сүрәсенең 25 нче аяте), - дигән.

("Фетнә" сүзенең башка төрле мәгънәләре дә бар: чуалыш, гауга, башбаштаклык, бозыклыкка өндәү, ара бозу, котырту. Юк-барга кызыгып, тугры юлдан язу, Җиһадта катнашудан баш тарту, Ватанга хыянәт, милләтнең бербөтенлеген таркатырлык гамәлләр кылу... Әйтик, бер шәхес, үз тормышын матди яктан баету өчен, халкының мәнфәгатьләрен сатса, бөтен халык, алар арасында гөнаһсызлар да, зыян күрә. Бу аятьнең тәрҗемәләрендә дә, тәфсирләрендә дә аерма шактый. Шуңа күрә, берничәсен мисалга китерү мәҗбүрендәбез.

И.Крачковскийда: "Бойтесь испытания, которое постигнет не только тех из вас, которые несправедливы": гаделләргә дә кагыла торган яман сынаулардан куркыгыз, ягъни Аллаһның сынауларыннан гаделләр дә куркырга тиеш.

Ш.Ногманида: "Зарары фетнәне булдыручыга гына булмыйча, бәлки зарары барыгызга да була торган фетнәне булдырудан сакланыгыз". Нәтиҗә: кеше урлашса, үзе генә гөнаһлы була; икәү зина кылса, икәвесе гөнаһлы була. Ләкин аңлы рәвештә дә, абайламастан да кылынган шундый ялгышлар, хаталар, гөнаһлар була, мондый гамәлләрне кылган кеше үзе генә Аллаһ каршысында гөнаһлы булып калмый, берничә кешегә, күп кешегә, бөтен халыкка, хәтта барча кешелеккә зыян салучы хаин, Иблискә тиң гунаһкяр була.)

Ачуланышулар, үзара аңлаша алмаучанлыклар, мөэминнәрнең берберсенә карата күралмаучанлыгы - Аллаһы Тәгаләнең инсаннарны сынавы ул. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) әйткән: "Мин Бөек Заттан өч (әйбер) сорадым. Ул миңа икесен бирде, берсен бирүдән баш тартты: мин Аннан кешеләрне корылык белән һәлак итмәвен үтендем, һәм Ул бу үтенечемне кире какмады; мин, шул ук вакытта, үз өммәтемне туфан белән һәлак итмәвен сорадым, Ул монысын да кире какмады; мин Аннан берсенең ачуын икенчесенә каршы кулланмауларын сорадым, тик ул минем бу үтенечемне үтәүдән баш тартты" (Мөслим, № 2890).

Үзебезнең мөэмин кардәшебезгә ачу тотаргамы-юкмы, яки үз ачу-ярсуларыбызны тыеп торыргамы икәнен без, һәм үзебез генә, сайлап ала алабыз. Бер-беребезне һәлак итеп без кая барып чыгарбыз соң? Бу турыда Аллаһы Тәгалә безне Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллә-ллаһу галәйһи үә сәләм (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) аша кисәтергә теләгән. Ул безгә: "Мөхәммәд! Әгәр дә Мин нинди дә булса карар кылганмын икән, ул - котылгысыз. Мин синең өммәтеңә, аңа олы казалар җибәреп аны һәлак итмәү бүләк иттем. Мин аны үз араларында булганнарыннан тыш, башка дошман хакимлегенә дә бирмәм, бар шәһәрләр дә аңа каршы чыгыш ясый башласалар да, һәм дә, алар бер-берсен әсир итә, харап итә башлаганга кадәр" (Мөслим, № 2889), - дип җиткергән.

Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) өммәте туган-туганга каршы үзара сугышлар башлаганга кадәр, аңа тышкы дошманнардан Аллаһның яклавы вәгъдә ителгән булган. Аллаһы Тәгаләнең ни өчен мөселман дөньясын төрле бәла-казаларга, басып алуларга дучар итүенең сәбәпләрен эзләп йөрисе юк. Без башта үзебез бер-беребезне һәлак итә башладык, һәм аннан соң безне һәлак итәр өчен башкалар килде. Фәлистыйнлыларның, гыйраклыларның, әфганстанлыларның, Кавказда яшәүче мөселманнарның бер-берләрен һәлак итүләрен искә төшерегез. Алар бер-берләрен һәлак итәләр, аннан соң аларны башкалар һәлак итә һәм алар шуннан соң Аллаһка ялвара башлыйлар, ә Аллаһы Тәгалә фетнә заманында ни булганы турында аларны алдан кисәткән иде бит. Барысы да фетнәдән башлана һәм ул Кыямәт көненең бер билгеседер.

Әгәр дә арабыздан пәйгамбәребез Мөхәммәд саллә-ллаһу галәйһи үә сәләмне (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) үз күзләре белән күргән, аннан Исламны өйрәнгән иң көчлеләребез дә тыелып, ызгыш коткысыннан котылып кала алмаган бер вакытта, безгә фетнәләрдән ничек сакланып калырга соң?

Әбу Һөрәйрадан (радыйАллаһу ганһу) җавапка охшаш мәгънәле сүзләр китерелгән: "Фетнәләр заманы килер, алардан батып баручының ялваруы кебек ялварудан башка берни дә коткарып кала алмас".

Бары тик гыйбадәт кылырга, котылуны өмет итеп, гыйбадәт кылырга гына.

Бәхәстә тыныч булырга, ашыгулардан сакланырга.

Ни сөйләгәнеңне хәтергә алып барырга, чөнки һәр каршылык сүздән башлана. "Башка бер мөэминнең каны, мөлкәте, намусы башка мөэмин өчен хәрам". (Мөслим)

Иң мөһиме - фетнәнең һәрберебездән башланып китеп, бар җәмгыятьнең таркалуына китерергә мөмкин икәнлеген истә тотарга. Һәм аны туктату өчен, һәр кешенең чын күңелдән каршылыкны киметүдә нәтиҗәле катнашуы кирәк. Әгәр барлык мөэминнәр дә бер-берсен үпкәләтә, ачуландыра торган бар сөйләшүләрдән дә кинәт кенә туктасалар, ничек яхшы булыр иде! "Мондый мөэмин - мин булам" дип һәрберсе сүздә һәм гамәлдә карар кылса, тагын да яхшырак.

**Нияз САБИРҖАНОВ**



# Камаллылар Туфан Миңнуллинның "мулла"сын көрәшче итеп күрә

**Камаллылар драматург Туфан Миңнуллинның "Мулла" спектаклендәге төп геройны яңа яктан ачып, персонажның холык-фигыленә үзгәрешләр кертеп, тамашачыларга тәкъдим итмәкче.**



Билгеле булганча, моңарчы бу спектакльне Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театры, Минзәлә дәүләт драма театры һәм Әтнә театры да куйды. Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театры моннан берничә ел элек спекакльне хәтта Г.Камал театры сәхнәсендә дә күрсәтте.

19 сентябрь көнне яңа 107 нче сезон ачылуга багышланган матбугат очрашуында театрның баш режиссёры Фәрит Бикчәнтәев билгеләп үткәнчә, ун елдан артык бара торган традиция буенча 7 ноябрьдә театрның элеккеге баш режиссёры, мәрхүм Марсель Сәлимҗановның туган көнендә драматург Туфан Миңнуллинның "Мулла" спектакле премьерасы була. "Үз вакытында Г.Камал театры труппасы Туфан Миңнуллинның "Дивана" спектакленә өстенлек биргән. Хәзер "Мулла" спектакленә тукталыр вакыт җитте. Моңа июльдә булган вакыйгалар да (19 июльдә мөфти Илдус Фәйзовка һөҗүм итү һәм Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге мөдире Вәлиулла Якуповны үтерү) этәргеч биргән булырга мөмкин. Билгеле: Туфан абыйның үлеме дә үзенең ролен уйнамый калмагандыр. Бу аның якты истәлегенә багышлана. Туфан Миңнуллин белән Марсель Сәлимҗанов дустанә иҗади мөнәсәбәтләрдә иде", - дип белдерде Ф.Бикчәнтәев.

Камал театрының баш режиссёры: "Туфан абыйның әсәренә

**(Ахыры 4 нче биттә.)**

# "Сабыйга" акциясе башлана!

**Ташландык балаларның гомерләренә битараф булмаучы һәм һәрдаим ярдәм кулы сузарга әзер торучылар игътибарына! 2012 елның 1 октябреннән 27 ноябрьгә кадәр "Болгар" радиосы һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге "Сабыйга" исемле хәйрия акциясе уздыра.**



Әти-әниләре ташлаган сабыйлар өчен көндәлек кирәк-яраклар җыела, мәсәлән: памперслар, туклану катнашмалары, кечкенә бала киемнәре, сабыннар, сабыйлар өчен присыпкалар, кремнар. Боларның барысы да психоневрологик авырулы 2 нче номерлы балалар йортына җибәреләчәк.

Ятим сабыйлар әти-әниләре тарафыннан кире кагылсалар да, Җир йөзендә ярдәм кулы сузарга әзер торучы мәрхәмәтле кешеләр күп. Сабыйларның гомеренә битараф калмассыз дип ышанабыз.

Балаларга ярдәм итәргә теләүчеләр бала кирәк-яракларын ТР мөселманнары Диния нәзарәтенә алып килә ала.

***Адресыбыз:** 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт.*

***Элемтәләр өчен телефон:** +7 (843) 264-61-58, 238-17-61.*

# УТТАН ДА КАЛА ИКӘН





Мамадыш районының Уразбахты авылында 1975 елда йортыбыз кара күмергә әйләнде. Әтием, берәр нәрсә сакланып калмады микән дип, кара булып тырпаеп торган хәрабәләр арасында эзләнеп йөрде. Һәм Коръән китабын табып алды. Әлеге китап сакланган шкафның күп өлеше һәм аның эчендәге башка китаплар көлгә әйләнгән, ә Коръән һәм ул куелган почмак янмый калган иде. Изге Китапның кырыйлары гына бераз көеп киткән, ул янгынчылар су сиптергәндә дә чыланмаган хәтта (сез аны рәсемдә күрәсез). Мин бу Коръәнне кешеләр күрсеннәр дип, мәчеткә тапшырмакчы идем, әмма абыстайлар аны өебездә сакларга киңәш иттеләр. Берничә елдан районыбызның имам-мөхтәсибе Илһам хәзрәт Миңнегалиевларның йортлары янды. Ул уттан исән калган Коръән китабын редакциябезгә алып килеп күрсәтте (мин район газетасында - "Нократ"та эшлим). Коръән - Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешеләргә җибәрелгән соңгы Китап, ул һәммәбезгә яшәү инструкциясе. Янгыннан соң өр-яңадан яшәп китү, аякка басу бик кыен, әлбәттә. Шулай да Ходай сабырлык, ярдәм бирде. Янгын, Коръән китабы белән бәйле шул очрактан соң мин күп нәрсәгә төшендем, дөньяга бөтенләй икенче күзлектән карый башладым, Мамадыш мәдрәсәсендә өч ел укыдым. Ният итеп намазга бастым, уразаларымны калдырмыйм.

***Фирая МИНГАЛИЕВА,***
***Мамадыш***

биттә.)

# Камаллылар Туфан Миңнуллинның "мулла"сын көрәшче итеп күрә

әлләни үзгәреш кертү кыен. Аның фикере, позициясе гел төгәл булып ярылып ята, аны үзгәртү бик авыр", - дип әйтсә дә, моңарчы куелган спектакльләрдәге мулланы бик пассив шәхес санаганга күрә, аны үзгә холыклы итеп яшәтергә тели.

"Без мулла образын конкретлаштырып бирергә телибез. Минемчә, бүгенге көндә дини мәсьәләләр, рухи көч турында сүз алып барсак, мулла көрәшче булырга тиеш. Дин, иман кебек глобаль төшенчәләр белән эш итүче кеше зур көчкә ия булырга тиеш. Теге спектакльләрдә мулла тыныч кына йөри, бернәрсә дә эшли алмый торган булдыксыз бер кеше булып күзаллана. Туфан абыйның әсәрендә "көрәшчелек" салынган дип уйлыйм һәм без аны тартып чыгарырга телибез. Акцент шуңа бирелә. Миңа калса, дин һәм иман төшенчәләре - икесе ике нәрсә. Туфан Габдулла улы бу хакта уйлангандыр кебек тоела", - дип хәбәр итте баш режиссёр.

Спектакльне куярга әзерләнгәндә "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе мөгаллимнәре белән консультацияләр алып барылган. Ә яшь артист Эмиль Талипов шундый көрәшә торган образны тудырырга әзерме соң? Аның персонажы катлаулы язмыш иясе, ул ата-анасыз үскән, яшүсмер килеш төрмәдә утырып чыккан. Образга керү һәм муллага "якынлашу" өчен, Эмиль Талипов хәзерге вакытта Коръән укый, намаз тәртибе өйрәнә, мәчетләргә йөри, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә консультацияләр ала икән.

Матбугат очрашуында аңлашылганча, бүгенге көндә Эмиль Талипов режиссёр ярдәме белән үзенең героен "тудыра" гына әле. Ул да аны көрәшче итеп күрергә тели.

"Мулла кем белән көрәшә?" дигән сорауга җавап биреп, артист гомуми генә итеп: "Имансызлык, чарасызлык, кыйбласызлык, кайбер вакытта үз-үзе белән", - диде.

***Римма ГАТИНА,***
***"Татар-информ" мәгълүмат агентлыгы***






## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 22.09.12 | 4:59 | 6:29 | 13:02 | 16:49 | 18:42 | 20:12 |
| Якшәмбе | 23.09.12 | 5:01 | 6:31 | 13:02 | 16:47 | 18:39 | 20:09 |
| Дүшәмбе | 24.09.12 | 5:03 | 6:33 | 13:02 | 16:45 | 18:36 | 20:06 |
| Сишәмбе | 25.09.12 | 5:05 | 6:35 | 13:02 | 16:43 | 18:34 | 20:04 |
| Чәршәмбе | 26.09.12 | 5:07 | 6:37 | 13:02 | 16:41 | 18:31 | 20:01 |
| Пәнҗешәмбе | 27.09.12 | 5:09 | 6:39 | 13:02 | 16:39 | 18:28 | 19:58 |
| Җомга | 28.09.12 | 5:11 | 6:41 | 13:02 | 16:38 | 18:26 | 19:56 |
| Шимбә | 29.09.12 | 5:13 | 6:43 | 13:02 | 16:36 | 18:23 | 19:53 |


**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 12 (155) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9417.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 20 сентябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).


**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**